| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__01__» ___04____ 2020 г. № _138____

«Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында (яңа редакциядә)» 2009 елның 23 апрелендәге 169 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опека яисә попечитель билгеләү һәм опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентын раслау турында» Министрлыкның 2019 елның 19 декаберендәге 2544 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында (яңа редакциядә)» 2009 елның 23 апрелендәге 169 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (2 нче кушымта) яңа редакциядә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20_20 елның «_1__» _апрелендәге_
_138_ номерлы карарына
кушымта

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) һәм суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән һәм опекага яки попечительлеккә алынган вакытта опекага алучы яки попечитель булырга теләк белдергән гражданнарның тормышына яки сәламәтлегенә карата аңлы җинаять кылган өчен хөкем ителмәгән балигъ булган хокукый сәләтле гражданнар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба – опека һәм попечительлек органы) тарафыннан опекага яки попечительлеккә мохтаҗ булган затның яисә опекун яки попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органының урнашу урыны: Балтач штп, Ленин урамы, 42 нче йорт, 202 нче кабинет.

Опека һәм попечительлек органының эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән кала, 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 11.45 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: ял көннәреннән тыш, һәр көнне.

Керү шәхесне ачыклаучы пропуск һәм (яки) документ буенча.

1.3.2. Белешмә өчен телефоннар: 2-51-36.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының (алга таба - Башкарма комитет) рәсми сайтының адресы: http://baltasi.tatarstan.ru

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) опека һәм попечительлек секторына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

1.3.5. Урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтның адресы, шулай ук башкарма комитетның электрон почтасы турында мәгълүмат опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1. пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба - РФ ГК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – СК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 31, 3824 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексы (алга таба-ГПК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №46, 4532 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба-РФ ТК)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1 (1 нче өлеш), 14 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба-3185-I номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясе Югары Советы һәм халык депутатлары Советы Җыелма басмасы», 1992, № 33, 1913 ст.);

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, № 17, 1755 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба - 601 номерлы Президент Указы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

«Балигъ булмаган хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле булган гражданнарга карата опека һәм попечительлек гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба-РФ № 927 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 48 ст. 6401, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары (алга таба-РФ Хөкүмәтенең 553 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 29, ст. 4479)

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы карары белән расланган балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданнарга опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу, исәпкә алу һәм әзерләү кагыйдәләренең 17 пунктын гамәлгә ашыру турында» 2011 елның 8 августындагы 891н номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының боерыгы (алга таба-891н номерлы боерык) (Россия газетасы, 2011, 28 сентябрь);

«Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән затның якын туганының тормыш шартларын тикшерү турында акт формасын раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 250н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының боерыгы (алга таба - 250н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2017, 27 июнь, бастырып чыгару номеры: 0001201706270021);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, 2004 ел, № 43-44, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы)(Татарстан Республикасы, 2008, № 60-61, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- 2005 елның 27 декабрендәге 23 номерлы Балтач район Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба - Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- 2008 елның 16 сентяберендәге 359 номерлы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган Балтач район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмә (алга таба - Опека секторы турында Нигезләмә);

– 2006 елның 29 декаберендәге 551 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Хезмәт регламенты (алга таба - Хезмәт регламенты).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека - суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру рәвеше, аның барышында опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекага алынганнарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик әһәмияткә ия булган барлык гамәлләрне башкаралар;

- попечительлек - суд тарафыннан хокукый сәләтлелек буенча чикләнгән гражданнарны урнаштыру рәвеше, аның барышында опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булганнарга РФ ГК 30 статьясы нигезендә гамәлләр кылу өчен ризалык бирергә тиеш;

- опекага алынган граждан - аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- хокукый сәләтсез граждан - РФ ГК 29 статьясында каралган нигезләр буенча суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип танылган граждан;

- хокукый сәләте чикләнгән - РФ ГК 30 статьясында каралган нигезләр буенча хокукый сәләте суд белән чикләнгән граждан.

- техник хата - дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) шулар нигезендә кертелә торган документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

удаленное рабочее место многофункционального центра предоставления государственных и муниципальных услуг – территориально обособленное структурное подразделение (офис) многофункционального центра предоставления государственных и муниципальных услуг, созданное в городском или сельском поселении муниципального района (городского округа) Республики Татарстан в соответствии с пунктом 34 Правил организации деятельности многофункциональных центров предоставления государственных и муниципальных услуг, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 22 декабря 2012 года № 1376 «Об утверждении Правил организации деятельности многофункциональных центров предоставления государственных и муниципальных услуг»;

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла.

Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт . |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Опека яки попечительлек билгеләү һәм суд тарафыннан хокукый сәләтсез яки хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булмаган зат өстеннән опекун яки попечитель билгеләү | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Балигъ яштәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданнарның опекуннары яисә попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу, исәпкә алу һәм әзерләү 927 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләр (алга таба - 927 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләр) |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Опека яисә попечительлек билгеләүгә мохтаҗ затның яки опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының | Устав;<br>№ 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 ст.; |

| | | |
|---|---|---|
| | опека һәм попечительлек Секторы. | № 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 ст.;<br>№ 48-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст.;<br>927 номерлы РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 4, 41пунктлары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү (1 нче кушымта) һәм билгеләнгән үрнәктә таныклык бирү (1 нче кушымта) яисә опека (попечительлек) билгеләүдән һәм опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карары | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 номерлы РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 пункты;<br>№8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 15 календарь көн.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша, электрон адреска) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла | № 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>927 номерлы РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 пункты. |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, | Гариза (2 нче кушымта). | РФ ГК; |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе. | Соңгы 12 айда уртача хезмәт хакы вазыйфасын һәм күләмен күрсәтеп, эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы гражданнар өчен - керемнәрнераслый торган башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгы күчермәләре) (аларны биргән көннән алып бер ел дәвамында кабул ителә).<br>Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә бирелгән, опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданны тикшерү нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе (аны биргән көннән 3 ай эчендә кабул ителә).<br>Язылышу турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән граждан никахлы булса).<br>Опекун булырга теләк белдергән граждан белән бергә яшәүче балигъ булган гаилә әгъзаларының, 10 яшькә җиткән балаларның фикерен исәпкә алып, балигъ булган опекага алынучының опекун белән бергә яшәвенә язма ризалыгы (опекун тарафыннан балигъ булган баланың опекун гаиләсе белән бергә яшәве турында карар кабул ителгән очракта).<br>927 номерлы Россия Федерациясе карары белән расланган Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә опекун булырга теләк белдергән граждан тарафыннан әзерлек узу турындагы документ (булган очракта);<br>Тәрҗемәи хәл.<br>Балигъ булган опекага алынучының опекуны яки попечителе булырга теләк белдергән ата-аналар, әбиләр, бабайлар, абыйлар, апалар, балалар һәм | РФ СК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 10 ст.;<br>927 номерлы РФ Хөкүмәтенең карарының 4, 41 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | оныклар (алга таба - опекун булырга теләк белдергән якын туганнар) опекага алынучы белән опекун итеп билгеләү турында гариза биргән көнгә даими рәвештә кимендә 10 ел бергә яшәгән булсалар, опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>1) гариза (2 нче кушымта);<br>2) балигъ булган опекага алынучы белән туганлыкны раслаучы документлар;<br>3) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә опекун булырга теләк белдергән гражданның медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе (аны биргән көннән 3 ай эчендә кабул ителә);<br>4) язылышу турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән якын туганы никахлы булса).<br>Гариза бирүче шәхесне раслаучы паспортны яки башка документны күрсәтә.<br>Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын опека һәм попечительлек органына шәхси мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Законда билгеләнгән тәртиптә расланган гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат); | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәреп.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә шушы документлар белән эш итүче оешма. | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>Мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр яисә торак урыныннан файдалану хокукын яисә торак урынына милек хокукын раслаучы документ, опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү урыныннан финанс шәхси счеты күчермәсе (вәкаләтле органнарда);<br>опекун булырга теләк белдергән гражданның аңлы рәвештә гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә җинаять кылган өчен хөкем ителмәве турында Эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән белешмәсе;<br>торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән белешмә (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча | № 927 номерлы РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган Кагыйдәләрнең 61 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | идарәсе);<br>Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнар тарафыннан пенсия алуны раслаучы белешмә - пенсионер булган опекун булырга теләк белдерүчегә карата;<br>опекун булырга теләк белдергән якын туганның, 18 яше тулганчыга кадәр вакытта, балигъ булган опекага алынучы белән үзен тиешенчә тотмавы турында фактлар булмау хакында опека һәм попечительлек органнарының бәяләмәсе.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирү яисә гамәлләрне башкару;<br>документлар һәм мәгълүмат тапшыру, шул исәптән, Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматлар тапшыру;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренчел баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыру | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>2. Бирелә торган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган төзәтмәләр булу.<br>3. Мөрәҗәгатьнең опека яисә попечительлек билгеләүгә мохтаҗ затның яки опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча булмавы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 номерлы РФ карары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гарызнамә биргәндә, мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта максималь көтү вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | 601 номерлы Президент Указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергәннән соң бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче икенче эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмати стендларга, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында күрсәтмә, текст һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шулай ук хезмәт күрсәтү урынына килү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында күрсәтмә (визуаль), текст һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның вакыт буенча озынлыгы күрсәткече, дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып, | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркем файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның кирәкле санда булуы;<br>башкарма комитетның мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүче сайлап алу буенча җирле үзидарә башкарма - боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә Федераль законның 151 статьясында каралган берничә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә аша (комплекслы гарызнамә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге яисә андый мөмкинлек булмау | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаларны электрон формада тапшыру мөмкинлеге;<br>.<br>инвалидларга, биналарга аларның керә алу мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән аларга хезмәтне алуга комачаулаучы башка тоткарлыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән билгеләнә:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен биргәндә чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы регламент нигезендә билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан сайтта, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында, алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша КФҮнең читтән торып эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гарызнамә составында күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстетриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) исәпкә алучы таләпләр һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша бирелергә мөмкин.<br>Гариза һәм документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | 63-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>553 номерлы РФ Хөкүмәтенең карары |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү, аларны теркәү;
- дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләрне формалаштыру һәм җибәрү;
- опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү;
- опекун (попечитель) билгеләү турында карар яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү;
- дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;
- техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Гариза бирүче шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша опека һәм попечительлек органына (алга таба – Сектор) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Сектор белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен, кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр бирелә.

Сектор белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте алу турында консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк очракта, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаларны һәм документларны кабул итү, аларны теркәү.

3.3.1 Гаризаны һәм документларны кабул итү буенча административ процедураны гамәлгә ашыра башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша яисә почта аша яки гаризаны һәм документларны шушы Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру турында хәбәрнамә белән, заказлы почта аша тапшыру тора.

Кабул итүне алып баручы Сектор белгече түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

документлар булу-булмавын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызып ташланган сүзләр һәм башка алдан әйтелмәгән төзәтмәләр булмау);

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, сектор белгече гариза бирү

ысулы буенча аны тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән, яки электрон формада карар һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итү турындагы тамга белән тасвирламаның күчермәсен бирә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Сектор белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Сектор белгече кергән гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән (мөрәҗәгать иткән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләрне формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Сектор белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге гарызнамәләрне җибәрә:

мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр яисә торак урыныннан файдалану хокукын яисә торак урынына милек хокукын раслаучы документ һәм опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү урыныннан финанс шәхси счеты күчермәсе (вәкаләтле органнарда);

опекун булырга теләк белдергән гражданның аңлы рәвештә гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә җинаять кылган өчен хөкем ителмәве турында белешмә (эчке эшләр органнарына);

торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында белешмә бирү хакында (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә);

пенсионер булган опекун булырга теләк белдергән гражданның пенсия алуын раслый торган белешмә бирү турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарына яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнарга);

опекун булырга теләк белдергән якын туганның, 18 яше тулганчыга кадәр вакытта, балигъ булган опекага алынучы белән үзен тиешенчә тотмавы турында фактлар булмау хакында опека һәм попечительлек органнарының бәяләмәсен бирү хакында (опека яки попечительлек билгеләүгә мохтаҗ затның элеккеге яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органнарына)

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) тапшыру турында гарызнамә.

3.4.2 Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән гарызнамәләр нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре

законда билгеләнгән вакытта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: Секторга җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә документларны (белешмәләрне) бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданның тормыш шартларын тикшерү.

3.5.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданны опекун итеп билгеләү максатларында (опекун булырга теләк белдергән якын туганнарыннан тыш), Сектор белгече аның яшәү шартларын тикшерә, тикшерү барышында Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән опекун (попечитель) итеп билгеләнүгә комачаулаучы шартларның булмавы билгеләнә.

Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданның тормыш шартларын тикшергәндә опека һәм попечительлек органы белгече торак-көнкүреш шартларын, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның опекун вазифаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасында килеп туган мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун яки попечитель булырга теләгән затның гаризасын теркәгәннән соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләгән затның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.2 Тикшерү нәтиҗәләре опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү турындагы актта (4 нче кушымта) (алга таба - гражданның тормыш шартларын тикшерү турындагы акт) күрсәтелә.

Тикшерү турындагы акт 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданга җибәрелә, икенчесе Секторда саклана.

Тикшерү турындагы акт буенча опекун булырга теләк белдергән граждан тарафыннан суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләгән затның яшәү шартларын тикшерү турында акт.

3.5.3. Опекун булырга теләк белдергән якын туганның опекун итеп билгеләү максатларында (опекун булырга теләк белдергән якын туганнарыннан тыш), Сектор белгече аның яшәү шартларын тикшерә, тикшерү барышында Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән опекун (попечитель) итеп билгеләнүгә комачаулаучы шартларның булмавы билгеләнә.

Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданның тормыш шартларын тикшергәндә опека һәм попечительлек органы белгече торак-көнкүреш шартларын, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның опекун вазифаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасында килеп туган мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун яки попечитель булырга теләгән якын туганның гаризасын теркәгәннән соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләгән якын туганның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.4. Тикшерү нәтиҗәләре опекун (попечитель) булырга теләк белдергән якын туганның яшәү шартларын тикшерү турындагы актта (8 нче кушымта) (алга таба - якын туганның тормыш шартларын тикшерү турындагы акт) күрсәтелә.

Тикшерү турындагы акт 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданга җибәрелә, икенчесе Секторда саклана.

Тикшерү турындагы акт буенча опекун булырга теләк белдергән граждан тарафыннан суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун (попечитель) булырга теләгән якын туганның яшәү шартларын тикшерү турында акт.

3.6. Опекун (попечитель) билгеләү турында карар яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.6.1 Сектор белгече опека һәм попечительлек комиссиясенә (алга таба - Комиссия) бирү өчен документлар пакеты формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм комиссиягә карап тикшерүгә җибәрелгән документлар пакеты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Утырышта Комиссия опекун (попечитель) билгеләү яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Опекун (попечитель) итеп балигъ булган хокукый сәләтле граждан гына билгеләнә ала. Шул ук вакытта аның әхлакый һәм башка шәхси сыйфатлары, опекун яисә попечитель бурычларын үтәүгә сәләте, мөрәҗәгать итүче һәм опекага яисә попечительлеккә мохтаҗ зат арасында булган мөнәсәбәтләр һәм, мөмкин булса, опекага алынучының теләге дә исәпкә алынырга тиеш.

Опека һәм попечительлек буенча Комиссия утырышын үткәрү барышы, шулай ук аның бәяләмәсе утырыш беркетмәсендә теркәлә. Күрсәтелгән беркетмәләр Комиссия утырышлары беркетмәләрен теркәү журналында теркәлә (№7 кушымта).

3.6.3 Комиссия әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар, әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктлары нигезендә алынган белешмәләр (документлар) һәм гражданның яшәү шартларын тикшерү турында акт (якын туганының яшәү шартларын тикшерү турында акт) нигезендә опекун (попечитель) билгеләү турында яисә опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, Комиссия тарафыннан опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турындагы карар кабул ителә:

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган яисә ялган белешмәләр ачыкланганда;

- мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 1.2 пункты таләпләренә туры килмәве (мөрәҗәгать итүчене суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип тану, мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе, опекун булырга теләк белдергән гражданның аңлы рәвештә гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә җинаять кылган өчен хөкем ителүе)

- конкрет гражданны опекун яисә попечитель итеп билгеләп кую опекага алынучы кешенең мәнфәгатьләренә туры килми торган хәлләрне ачыклау (закон белән йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелү; опекун бурычларын үтәүгә комачаулаучы авыру белән интегү; даими яшәү урыны булмау, санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килми торган торак биналарда яшәү)

- гражданның (якын туганының) Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән, аның опекуны итеп билгеләнүгә комачаулаучы хәлләр булуы чагылдырылган яшәү шартларын тикшерү акты.

Комиссия утырышының нәтиҗәсе - беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана торган карарны кабул итү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.4. Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә белгеч Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү турында (1 нче кушымта) карары проектын яисә опека (попечительлек) билгеләүдән һәм хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән граждан өстеннән опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә имза куюга җибәрә. Карар ике нөсхәдә төзелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: җитәкчегә кул куюга юлланган карар проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.5. Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе Комиссия утырышы беркетмәсен карый һәм опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү турында карарга (алга таба –Билгеләү турында карар) яисә опека (попечительлек) билгеләүдән, хокукый сәләтсез яки хокукый сәләте чикләнгән граждан өстеннән опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карарга (алга таба – Баш тарту турында карар) кул куя.

Процедураның нәтиҗәсе: 2 нөсхәдә имзаланган карар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.6. Сектор белгече теркәү журналында билгеләү турында Карарны терки, билгеләнгән үрнәктәге таныклыкны (3 нче кушымта) рәсмиләштерә.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.7 «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында билгеләнгән очракларда, түләүле нигездә опека башкару турындагы гариза нигезендә опека һәм попечительлек органы үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкаручы опекун билгеләү турында карар кабул итә һәм 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданга карата опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзи.

3.7 Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Билгеләү турында карарның һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклыкның яки Баш тарту турында карарның бер нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә ул килгән көнне бирелә.

Опека һәм попечительлек органы мөрәҗәгать итүчегә Баш тарту турында карар белән бергә тапшырылган барлык документларны кире кайтара һәм шикаять бирү тәртибен аңлата. Күрсәтелгән документларның күчермәләре опека һәм попечительлек органында саклана.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән Билгеләү турында карар һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклык яки Баш тарту турында карар.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

3.8 Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Секторга түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (8 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы булган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

техник хаталар булуны дәлилләүче юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшырыла.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны терки һәм аларны Секторга тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Сектор белгеченә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.8.3. Сектор белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.6.4-3.6.6 пунктларында каралган процедуралар башкара һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алу шарты белән шәхсән үзенә имза куйдыртып бирә, яисә мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Секторга биргәндә документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта аша) хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыклангannan соң яки җибәрелгән хата турында кызыксынган затлардан гариза алганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүдән, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүдән гыйбарәт.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Проектларны визалау тикшерү нәтиҗәсе булып тора;

2) билгеләнгән тәртиптә эш башкаруны алып бару буенча тикшерүләр үткәрү;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча карала ала.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрне башкаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, шулай ук опека белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесенең урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплы була.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы була.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү буенча судка кадәрге (судтан тыш) тәртип.

5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы башкарма комитет хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) башкарма комитетка, башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренщ (гамәл кылмавына) - муниципаль берәмлек Советына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәү вакытын үтәмәгәндә;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын үтәмәгәндә;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшырылуы яки башкарылуы каралмаган документларны яисә мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүчедән тапшырылуы Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тартканда;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән

документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләр билгеләнгән вакытка үтәлмәгәндә;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле булган, булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматны таләп иткәндә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Балтач муниципаль берәмлегенең (http://baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин. .

5.3. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән, яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта, яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр яки мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефоны номеры (номерлары), мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслаучы документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Мөрәҗәгать итүчегә әлеге  пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирәләр, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүче кылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтәләр.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлегенең
башкарма комитеты

**КАРАР**

№_____ _____________

**Опека (попечительлек) һәм хокукый сәләтсез, хокукый сәләте чикләнгән затка опекун (попечитель) билгеләү турында**

___________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______ елда туган,

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(даими яшәү урыны адресы-өлкә, шәһәр, район, урам, йорт номеры, фатир номеры)

адресы буенча яшәүче,

___________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне)

гаризасын карап тикшереп,

______________________________ _________________________________

(суд карары датасы) (судның исеме)

суды карары белән хокукый сәләтсез, өлешчә хокукый сәләтле дип билгеләнгән, туганлык мөнәсәбәтләрен, әхлакый сыйфатларны исәпкә алып, ___________________________________________________________________________,

тапшырылган документлар, Россия Федерациясе Граждан кодексына таянып,

__________ елда туган

___________________________________________________________________________

(хокукый сәләтсез затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне)

өстеннән опекун (попечитель) итеп билгеләү турында

КАРАР БИРӘМ:

1. Опека, попечительлек билгеләргә һәм _______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________________________ өстеннән

(хокукый сәләтсез затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

опекун яисә попечитель итеп билгеләргә.

2. Опекунга, попечительгә опекага алынган баланың хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, тәрбияләү, дәвалау бурычларын башкарырга.

3. Опекунга, попечительгә ел саен агымдагы елның **1 февраленнән дә соңга калмыйча** опека һәм попечительлек Секторына алдагы ел өчен тәрбиядәге баланың мөлкәтен саклау, аның белән файдалану һәм идарә итү турында хисап тапшырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә______________________________________.

(фамилия, инициаллар)

Җитәкче ______________/ ______________________________

(имза) (фамилия, инициаллар)

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Опека һәм попечительлек Секторы исеме
___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданлыгы, шәхесне раслаучы документ
(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән балигъ яшьтәге гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның фактта яшәү урыны адресы)

Хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән балигъ яшьтәге гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән граждан
Гаризасы

Мин, _________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________
(балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яки өлешчә хокукый сәләтле гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, ае, елы)

☐ миңа опекага (попечительлеккә)*
__________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
(балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яки өлешчә хокукый сәләтле гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, ае, елы)

☐ миңа түләүле нигездә опекага (попечительлеккә)*
тапшыруыгызны сорыйм.

Матди мөмкинлекләр, торак шартлары, сәламәтлек торышы һәм эш характеры миңа балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яки өлешчә хокукый сәләтле гражданны опекага (попечительлеккә) алырга мөмкинлек бирә*.

Үзем хакында өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне хәбәр итә алам:
______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(гражданда балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яки өлешчә хокукый сәләтле граждан өстеннән опека (попечительлек) башкаруда кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр, шул исәптән һөнәри эшчәнлек турында документлар булуы, опекунга яки попечительгә кандидатлар әзерләү программаларын узу турында мәгълүмат һ. б. күрсәтелә.)

Мин, ______________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

әлеге гаризамдагы һәм минем тәкъдим иткән документларымдагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм куллануга ризалык бирәм.

______________________

(имза, дата)

________________________________

* (кирәкмәгәнен сызарга)

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

ТАНЫКЛЫК

Әлеге таныклык ___________________________________________
адресы буенча яшәүче, гражданга:
____________________________________________________________
(опекунның, попечительнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең карары нигезендә
________________________ номерлы ______________________________
(суд карары датасы) (суд исеме)
суды карары белән билгеләнгән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән (кирәклесенең астына сызарга)
____________________________________________________________
адресы буенча яшәүче
____________________________________________________________
(хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы)
өстеннән опекун, попечитель итеп (кирәклесенең астына сызарга) билгеләнүе турында раслап бирелде.

Гамәлдә булу вакыты___________________________________________.

Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлекнең
башкарма комитеты
җитәкчесе ______________/ ________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Форма Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2017 елның 9 мартындагы 250н номерлы боерыгы белән расланган

Опека һәм попечительлек
органы бланкы

**Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү акты**

Тикшерү датасы "___" ________ 20__ ел

Тикшерү үткәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________.

____________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне)

тормыш шартларын тикшерү үткәрелде.

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның шәхесен таныклаучы документ

_______________________________________________________________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның факттагы яшәү урыны һәм яшәү шартларын тикшерүне уздыру урыны

____________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның белеме

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Профессиональ эшчәнлек* ____________________________________________

_____________________________________________________________________

(балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның, адресын, вазифасын, эш телефонын күрсәтеп, эш урыны)

_____________________________________________________________________

(балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
яши торган торак мәйдан ____________ кв.м тәшкил итә, ___________ бүлмәдән тора, ______ катлы йортның ______ катында һәр бүлмәнең зурлыгы: ______ кв. м, ________кв. м, _______ кв. м.

Йортның сыйфаты (кирпечтән, панельле, агач һ.б.; нормаль халәттә, тузган, авария хәлендә; бүлмәләр коры, якты, үтеп йөрү бүлмәләре, тәрәзә саны һ.б.).

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(кирәклесен күрсәтергә)

Йортны һәм торак мәйданны (суүткәргеч, канализация, нинди җылылык, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.) төзекләндерү________________________________.

(кирәклесен күрсәтергә)

Торак мәйданның санитар-гигиена торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел) _____________________________________________

(кирәклесен күрсәтергә)

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле граждан өчен аерым бүлмә булу (опекун (попечитель) белән бергә яшәгән очракта)**

______________________________

Торак мәйданда түбәндәгеләр яши (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм фактта яшиләр):

| Фамилия, исеме, атасының исеме | Туган елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәте | Әлеге торак мәйданда кайчаннан яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданның гаилә әгъзалары арасында урнашкан мөнәсәбәтләр

_____________________________________________________________________

(үзара мөнәсәбәтләр характеры, гаилә әгъзалары арасында аралашу үзенчәлекләре һ. б.)

Гражданинның шәхси сыйфатлары (характерның үзенчәлекләре, гомуми культурасы, балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданнар белән аралашу тәҗрибәсе булу һ.б.)

______________________________________________________________________

Хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның мотивлары**

______________________________________________________________________

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматлары _________________________________

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның яшәү шартлары

______________________________________________________________________

(канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел, конкрет хәлләрне күрсәтеп)

Тикшерү үткәргән затның имзасы ______________________________________

(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе вазыйфасы)

__________________ ____________________

(имза) (Ф. И.А.)

М.У.

________________________________

*Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны (попечителе) булырга теләк белдергән граждан эшләмәүче пенсионер булмаса, әлеге юлда «пенсионер, эшләмәүче» күрсәтелә.

** Кирәкмәгәнен сызарга

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны (попечителе) булырга теләк белдергән гражданнарны исәпкә алу журналы

Башланды:___________________

Тәмамланды:_________________

| N т/б | Ф.И.А. туган көне | Яшәү урының почта адре-сы, телефо ны(эш неке, өйне-ке) | Гаилә хәле | Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны (попечителе) булырга теләк белдергән гражданның гариза бирү датасы | Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү датасы һәм нәтиҗәләре (Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү акты нигезендә) | Опекунны билгеләү яки опекунны билгеләүдән баш тарту турында актның датасы һәм номеры яки мөрәҗәгать итүченең опекун булу мөмкинлеге яки мөмкинлеге булмау турында бәяләмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле затларның шәхси эшләрен исәпкә алу һәм теркәү журналы

| № | Хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле затның Ф. И.А., өй адресы | Суд карары реквизитлары (датасы, суд исеме, үз көченә керү датасы) | Опекун булырга теләүченең Ф.И.А., өй адресы | Опека һәм попечительлек комиссиясе карарының датасы һәм эчтәлеге | Опекунлыкны, попечительлекне билгеләү (туктату) турында күрсәтмәнең датасы һәм номеры | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Опека һәм попечительлек буенча комиссия утырышлары беркетмәләрен теркәү журналы

| т/б № | Комиссия утырышы датасы | Аңа карата мәсьәлә каралучы хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле затның Ф.И.А. | Опека һәм попечительлек буенча комиссия утырышының көн тәртибе эчтәлеге | Каралган мәсьәлә буенча опека һәм попечительлек комиссиясе карарының эчтәлеге | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Форма Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2017 елның 9 мартындагы 250н номерлы боерыгы белән расланган

Опека һәм попечительлек
органы бланкы

# БАЛИГЪ ЯШЬТӘГЕ ХОКУКЫЙ СӘЛӘТСЕЗ ЯИСӘ ӨЛЕШЧӘ ХОКУКЫЙ СӘЛӘТЛЕ ГРАЖДАННЫҢ ОПЕКУНЫ ЯИСӘ ПОПИЧИТЕЛЕ БУЛЫРГА ТЕЛӘК БЕЛДЕРГӘН ЯКЫН ТУГАНЫНЫҢ ЯШӘҮ ШАРТЛАРЫН ТИКШЕРҮ АКТЫ

Тикшерү датасы "_____" _____________ 20_____ ел

Тикшерү үткәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(балигъ яшьтәге хокукка сәләтсез яисә тулысынча хокукый сәләтсез гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән якын туганының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы) яшәү шартларын тикшерү уздырылды.

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән якын туганның шәхесен раслаучы документ

_______________________________________________________________________

(исеме, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

________________________________________________________________

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән якын туганның яшәү шартларын фактта яшәү һәм тикшерү уздыру урыны:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

Торак мәйданда түбәндәгеләр яши (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм фактта яшиләр):

| Фамилия, исеме, атасының исеме | Туган елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәте | Әлеге торак мәйданда кайчаннан яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны булу теләген белдергән якын туганының опекун итеп билгеләп куюга комачаулаучы Россия Федерациясе Граждан кодексында (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, N 32, 3301 ст; 2008, N 17, №1756) билгеләнгән хәлләр булмау/булу турында мәгълүмат ____________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

Балигъ яшьтәге хокукый сәләтсез яисә өлешчә хокукый сәләтле гражданның опекуны яисә попечителе булу теләген белдергән гражданның яшәү шартлары

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел, конкрет хәлләрне күрсәтеп)

______________________________ ___________ ___________

(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе вазыйфасы) (имза) (Ф.И.А.)

М.У.

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Техник хатаны төзәтүгә гариза

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________(хатаның төре)

Язылган:___________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:__________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтеп, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны кушып бирәм

1.
2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

E-mail адреска электрон документ җибәрү юлы белән:_________________________

Түбәндге адрес буенча почта аша кәгазь чыганактагы таныкланган күчермә рәвешендә:

____________________________________________________________________________.

Үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның шәхси мәгълүматларын (җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, таралуны (шул исәптән тапшыруны), ярлыландыруны, блоклауны, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруны, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару) эшкәртүгә ризалыгын, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, карарларны алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында кабул итүне дә кертеп, раслыйм.

Раслыйм: минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителә торган затка караган гаризаларга кертелгән белешмәләр, шулай ук түбәндә язылган белешмәләр дөрес. Гаризага кушымта итеп бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза бирелгән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләргә ия.

Түбәндәге телефон аша миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм ______________________________.

Датасы_________________ Имза_______________/_______________________
Хезмәт билгеләре Гариза керде: Датасы:

Керү номеры
Гаризаны кабул итүче затның Ф.И.А. һәм имзасы

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
10 нчы кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Балтач район башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **25134** | Aydar.Hayrutdinov@tatar.ru |
| Гомуми оештыру бүлеге башлыгы | **26084** | Baltasi.Rayispolkom@tatar.ru<br>Nurgaliev.Ramil@tatar.ru |
| Опека һәм попечительлек секторы (бүлеге) белгече | **25136** | Baltasi.Opeka@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Балтач район Советы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **24450** | Baltasi.Priemnaya@tatar.ru |